**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» август, 2024 ел № 593-п

Гражданнар керменең һәм 2025 елның өченче кварталына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы, 2007 елның 13 июлендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә – «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының күрсәтелгән кушымтада бәян ителгән чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы белән «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлык хаты белән, 14.02.2025 ел, № 73, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен 2025 елның 3 кварталына чик күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен-3 688 129,5 сум
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен-4 693 983,00 сум
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен-6 035 121,00 сум
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен-8 046 828,00 сум
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен-10 058 535,00 сум
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен-12 070 242,00 сум
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен-14 081 949,00 сум

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына килә торган уртача айлык керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен-40 270,45 сум
1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен-25 626,65 сум

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 21 965,70 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне гражданнарны муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемлеләр дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И. Р. Дәүләтханов